КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 14 май г.Казань № 388

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Укыту-тәҗрибә Лубян урман хуҗалыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2020 ел, 25 гыйнвар, 22 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Укыту-тәҗрибә Лубян урман хуҗалыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2020 ел, 25 гыйнвар, 22 нче карарына, 3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Учреждениенең үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт гербы сурәте төшерелгән түгәрәк мөһере, штамплары һәм бланклары бар.».

2. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына «Укыту-тәҗрибә Лубян урман хуҗалыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе уставын бу карарга туры китерүне тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин